# ЧИШМӘ БАШЫ

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы «МӨНДЕШ БАЛАЛАР БАКЧАСЫ»МБМББУ, гыйнвар, 2025 ел № 3




*Ата-аналар һәм балалар өчен мәгълүмати-танып белү газетасы*

## Газетаның сәхифәләре:

* Кышкы чорда куркынычсызлык чаралары.
* Без бергә! (МХО катнашучыларга гуманитар ярдәм)
* Балалар бакчасында сөйләм телен үстерү.
* “Тылсымлы су. Суның үзенчәлекләре” (эксперименталь шөгыль сценарие)
* Кыш турында сынамышлар

**Баш мөхәррир:**
**балалар бакчасы мөдире**
**Мостафина Рима Галип кызы.**
**Мөхәррир урынбасарлары:**
**музыка җитәкчесе Хөсәенова Г.Ф.**
**тәрбиячеләр: Хөсәенова Р.Р.,**
**Җәләлиева А.Г., Шәкүрова Р.С.**

# *Кышкы чорда куркынычсызлык чаралары.*

*Кыш - тылсымлы вакыт. Кыш - хуш исле чыршылар, күңелле бәйрәмнәр вакыты. Ләкин кыш үз куркынычларын китерә. Елның салкын вакытында иминлекне саклау өчен киңәшләр.*

***1. Баланы урамга ничек дөрес киендерергә:*** баланы урамга җибәргәнче аның ничек киенгән карагыз: җылы, берничә кат кием. Мөмкин кадәр йонлы киемнәр сайлагыз. Кышкы кием баланың зурлыгына туры килергә тиеш һәм хәрәкәтләрне чикләргә тиеш түгел. Бу аеруча аяк киемнәре өчен актуаль. Артык кысан итекләр кан басымын тарайталар, нәтиҗәдә аяклар тизрәк суыналар. Аяк киемен сайлаганда бер размерга зуррак алыгыз.

2. ***Чанада шуу:*** Балалар чанада шуарга яраталар. Чанада шуа торган урын ачык булырга тиеш. Баланың юлында агачлар һәм куаклыклар булмаска тиеш.

***3. Әгәр дә бала өшесә:***

- җәрәхәтләнгән өлешләрне чиста йомшак тукыма белән уыгыз, кар белән умагыз;
- салкын һәм юеш киемнәрне коры, йомшак, иркен киемгә алыштырыгыз;
- организмны акрынлап җылытыгыз: какао яки чәй эчерегез;
- ярдәмгә табипны чакырыгыз.

***4. Шарф, бияләйләр һәм перчаткалар.*** Шарфны кием эченә кертеп калдырыгыз. Өстәмә бер кием перчаткалар яки бияләйләр булырга тиеш, чөнки перчатка югалырга, яки чыланырга мөмкин. Саф һавада уеннар чыныгу һәм профилактика өчен бик мөһим.



## *БЕЗ БЕРГӘ!*

Билгеле булганча, Россия Федерациясе Президенты Владимир Путин 2025 елны Ватанны саклаучылар елы дип игълан итте. Безнең районда да шушы уңайдан күп чаралар планлаштырыла, 26 гыйнварда районда шушы елны ачуга старт биреләчәк.

Быел Бөек Ватан сугышында Җиңүгә 80 ел тула. Махсус хәрби операция дәвам итә. Анда безнең районнан йөзләгән батыр ир-егетләребез катнаша. Ә гуманитар ярдәм күрсәтүгә бөтен район күтәрелде. Һәркем үз өлешен кертергә омтыла, моңа мисаллар бик күп.

Районда Ватанны саклаучылар елын ачу махсус хәрби операциядә катнашучыларга гуманитар ярдәм колоннасын озату белән башлана. Колоннаны озату тантанасы шәһәрнең үзәк мәйданында үтәчәк. Хәзер менә шул колоннаны туплау бара һәм аңа һәркем үз өлешен кертә ала.










Без дә бу эштән читтә калмадык. Гуманитар ярдәм җыюда катнашкан балалар бакчасы коллективына, әти-әниләргә, авылдашларга зур рәхмәтебезне җиткерәбез! Бердәм булып, кулыбыздан килгәнчә ярдәм итик. Егетләребез туган якларына исән-имин әйләнеп кайтсыннар иде.

## *Балалар бакчасында бәйләнешле сөйләм телен үстерү алымнары*

Балаларны туган телдә сөйләшергә өйрәтү – мәктәпкәчә белем бирү учреждениеләренең төп бурычларыннан берсе. Балачак чоры – үзе бер кабатланмас, сихри дөнья. Бу чор баланың шәхес буларак формалашуында мөһим этап булып тора. Шушы вакытта ул әйләнә-тирә мохиткә җайлаша, күзәтә, үзенә үрнәк ала.
Балалар бакчасындагы ана теленнән шөгыль татар балаларына милли тәрбия бирүне, сөйләм телен үстерүне максат итеп куя. Бала ана телендә яхшы сөйләшә, аралаша белгәндә генә үзенең фикерен ачык, төгәл һәм дөрес әйтеп бирә ала. Дәресләрне кызыклы, мавыктыргыч итеп оештыру мөһим роль уйный.

Яңа материалны аңлату, ныгыту, үткәннәрне кабатлау, балаларны дөрес сөйләм үрнәкләренә өйрәтү, эшчәнлекләрен активлаштыру төрле алымнар һәм чаралар ярдәмендә тормышка ашырыла. Яшь үсентеләргә җылы кояш, уңдырышлы яхшы туфрак кирәк булган кебек балаларга да үсү, чыныгу өчен яхшы җирлек кирәк. Татар халкының буыннан-буынга күчеп килгән иҗат җәүһәрләре балаларыбыз өчен зур тәрбия хәзинәсе булып тора. Яшь үзенчәлекләрен исәпкә алып, аларны дөрес сайлый белергә генә кирәк. Хәзерге зур үзгәрешләр чорында милли гореф-гадәтләрне, йолаларны өйрәтү – бик кирәкле һәм әһәмиятле эш. Татар халкын милләт буларак саклап калу, рухи мирасны алдагы буыннарга тапшыру – балалар бакчалары тәрбиячеләренең дә төп вазифаларыннан берсе.

Шөгыль вакытында балалар белән татар телендә генә сөйләшергә тырышам. Төрле шигырьләр, бигрәк тә әкият укуга зур игътибар итәм. Әкият геройлары булып уйнау, алар булып сөйләшү балаларга бик ошый. Уеннар, мавыктыргыч күнегүләр, табышмак, башваткыч, кызыклы әңгәмәләр һәм мәзәкләр балада ана теленә мәхәббәт тәрбияли, телгә карата тирән кызыксыну уята.



Балаларны уенга җыя белү дә зур әһәмияткә ия. Моны төрле юллар белән эшләргә мөмкин. Мәсәлән, тәрбияче алдан уен башлануының билгесе буларак кул чаба, кыңгырау чыңлата һ.б. Уенның исеме әйтелә. Эчтәлеге кыскача, аңлаешлы, балаларның исләрендә калдырырлык, игътибарларын җәлеп итәрлек, кызыклы итеп аңлатыла.

Драматик уеннардан сюжетлы-рольле уеннар балаларны сөйләү осталыгын үстерүгә уңай йогынты ясый. Сөйләм телен үстерүдә, дөрес итеп сөйләргә өйрәтүдә сүзле уеннарның да роле зур. Уен барышында балалар сүзләрне күмәк төстә кабатлыйлар, яңа сүзләрне дөрес әйтергә өйрәнәләр, бер-берсе белән аралашалар. Уен нәтиҗәле булсын өчен, аны үткәрүгә уңай шартлар тудырылган булырга тиеш. Төрле костюмнар, битлекләр, җиһаз-предметлар алдан әзерләп куела.

Кулланыла торган әйберләр балаларның игътибарын җәлеп итәрлек ачык төстә, матур булырга тиеш. Тәрбияченең дә уенда катнашуы балаларга бик уңай тәэсир итә. Уен барышында тәрбияче уенда катнашучыларны игътибар белән күзәтә, уен кагыйдәләренең төгәл үтәлүен контрольдә тота, аннан соң балаларның эшчәнлеген бәяли.

Нәтиҗә ясап шуны әйтергә кирәк: төрле алымнар кулланып, сөйләм телен үстерү балаларның сүзлек байлыгын арттыра, тел элементларын дөрес, төгәл, урынлы кулланырга мөмкинлек бирә. Балалар коллективта үзләрен ышанычлырак тотарга өйрәнә, аларның эчке дөньясы, сәләте ачыла. Балаларда туган теленә – татар теленә карата мәхәббәт уяна. Болардан тыш, тәрбияче балалар белән уйный торган барлык уеннарны яхшы белергә, аларны оештыру өчен бөтен белемен, фантазиясен, иҗади мөмкинлекләрен файдаланырга тиеш.



***Тылсымлы су.***
***Суның үзенчәлекләре***
*(мәктәпкә әзерлек һәм зурлар*
*төркемендә  экологик тәрбия буенча эксперименталь шөгыль)*

***Тема:*** **Тылсымлы су. Суның үзлекләре.**
***Максат:*** **1. Балаларга суның кеше тормышында әһәмиятле роль уйнавын күрсәтү. Суга сакчыл караштәрбияләү.**
**2. Балаларның игътибарын суның гади, таныш нәрсә булуына карамастан, аның серле, тылсымлы булуына юнәлдерү. Суның табигатьтә төрле рәвештә очравына ышандыру.**
***Җиһазлау:*** **Тамчыкай (картоннан); "Су" темасы буенча слайдлар, су тавышлары язмасы, глобус, магнитофон, экспериментлар өчен җиһазлар (үтәкүренмәле стаканнар, сөт белән стакан, трубочкалар, шикәр, кашык, боз кисәкләре,кайнар су белән термос, көзге )**

**Эшчәнлек барышы.**

**Тәрбияче.** Балалар, шөгылебезне башлыйбыз. Безгә бүген кунаклар килгән, әйдәгез, алар белән исәнләшик.

**Балалар.** Исәнмесез.

**Тәрбияче.** Балалар, мин сезгә бер табышмак әйтәм, җавабын тапсагыз, бүген нәрсә турында сөйләшәчәгебезне аңларсыз.

Елга-диңгездә яши, һавада җиңел оча.
Әгәр очып арыса, кабаттан җиргә төшә.

**(су, су тамчысы)**

**Тәрбияче.** Әйе, балалар, бик дөрес. Су! Без бүген су турында сөйләшербез.  (*Тамчы тамган тавыш ишетелә).*

**Тәрбияче:** Балалар, сез бернинди дә тавыш ишетмисезме? Миңа әнә шул яктан кемдер эндәшкән кебек булды. Карыйм әле, мөгаен анда кемдер бардыр… (Тәрбияче яшергән җирдән су тамчысын алып килә) Менә нәрсә булган икән ул, балалар! Сез аны танийсызмы? Әйе, бу – тамчы, су тамчысы, шулай бит. Ул бүген су турында сөйләшүебез турында ишеткән дә безнең янга килергә булган. Әйдәгез, без аны менә монда урнаштырыйк, ул безне карап, тыңлап торсын, ярыймы?



**Тәрбияче.** Белгәнебезчә, без Җир планетасында яшибез. Җирдә суны кайларда очратырга мөмкин икән, искә төшереп китик *әле (“Су”темасы буенча слайдлар карау: диңгез, елга, инеш, күл, чишмә, сазлык һ.б.. Һәр рәсем буенча балаларның җаваплары тыңлана.)*
**Тәрбияче.** Ә хәзер сезнең игътибарлылыгыгызны тикшереп алыйк. Тыңлагыз һәм нәрсә тавышын ишетүегез турында кул күтәреп җавап бирегез.
***Уен: “Нәрсә тавышы?”***
*Балаларга тыңлау өчен диңгез шаулаганы, чишмә челтерәве, яңгыр тавышы, тамчы тамган тавыш тәкъдим ителә.*
***“Су нәрсәләргә, кемнәргә кирәк?” дидактик уен.*** (Туплы уен).
Слайд карау. «Су кемнәргә, нәрсәләргә кирәк?»

Су – бөтен тереклек өчен кирәк, су үсемлекләргә дә, хайваннарга да, кешеләргә дә яшәү чыганагы булып тора.
**Тәрбияче:** Балалар, тамчы безгә буш кул белән килмәгән. Шундый матур папка алып килгән. ***(Тамчыкай** алып килгән рәсемнәр буенча җөмләләр төзибез. Балаларга рәсемнәр таратам. Һәр бала үзенең рәсеме буенча җөмлә төзеп әйтә)*. Менә, балалар, су безне эчертә дә, ашата да, юындыра да икән. Су безнең сәламәтлек турында кайгырта, ул безгә чиста, матур йөрергә, чыныгып үсәргә булыша икән.
**Тәрбияче.** Балалар, аңладыгызмы, безнең өйләргә килеп җиткәнче Су тамчысы үзенең дуслары белән никадәр юл үтә икән. Шуна күрә чиста суны юкка-барга әрәм итәргә ярамый.
***Йомгаклау.***
**Тәрбияче**: Балалар, без сезнең белән бүгенниләр турында сөйләштек? *(Төрле ел фасылларында су буенда үтәлергә тиешле куркынычсызлык кагыйдәләрен кабатлау. Җәй көне су коенганда үтәргә кирәк булган саклык чаралары турында рәсемнәр карау*)



**Кагыйдә:**
1. Суга сакчыл караш булдыру, краннан суны ничек агызсаң, шунда ук кранны яхшылап ябып куй.
2. Суга теләсә-нинди әйберләр атма.
3. Үзеңнең артыңнан пычрак калдырмаска.
4. Су кеше тормышында иң кирәкле чыганак икәнен онытмаска кирәк.

**Тәрбияче:** Әйе, кеше тормышында су бик зур роль уйный. Су булмаса, барлык тереклек үлеп бетәргә мөмкин. Шуңа күрә һәрбер кеше, өлкәнме, баламы, суны сакларга, аңа карата мәрхәмәтле булырга тиеш. Шулай булганда гына су бөтен байлыгын безгә кешеләргә бирә.










# *КЫШ ТУРЫНДА СЫНАМЫШЛАР*

***Татар халкы табигатьтәге үзгәрешләргә элек-электән игътибар иткән һәм алдагы көн, ай һәм, хәтта, елда һава торышы нинди булачагын алдан сыный торган булган...***

– Болытлар түбәннән килсә, каты суыкны көт.
– Кыш көне болытлар юлланып торса, җәй җылы булыр.
– Кышның төньяк бураннары ашлык җыйганда яңгыр китерер.
– Көн озая башлагач, гыйнвар башында, бәс төшсә, җәй ашлык чәчкәндә чык булыр.
– Гыйнварның егерме дүртендә булса аяз, бик нәфис килер яз.
– Кыш бәс, томан булса, җәй иген уңа.
– Кыш көне яңгыр яуса, икмәк булыр.
– Кыш сыкы булса, җәй алма була.
– Кыш томан булса, җәй юкәдә бал була.
– Әгәр кар вак кына бөртекле, сирәк кенә төшкәләсә, бик озак суык булыр.
– Кыш кар күп булса, җәй яңгырлы булыр.
– Әгәр елга суы боз өстенә чыкса, көн җылытыр.
– Тоз юеш булса, кыш көне җепшек була.
– Утын сызгырса, көн суытыр.
– Тау башларында кар күп булса, җиләк күп булыр.





## СЫНАМЫШЛАР

1. Чыпчыклар кыш көне җыелышып бер урында чыркылдашсалар, җылы булып кар явар.





2. Кара карга килгәч, бер айдан кар китәр.



3. Кошлар кар өстенә төшсә, көн җылыта.

4. Карлыгач кышларга иртә китсә, кыш суык, озак булыр.



5. Суган кабыгы калын булса, кыш салкын була.



